СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 4-05-21; e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар  Решение

20 июнь 2023 ел  №2-26

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль милкенә карата концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендәКатмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Катмыш авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсмиmamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Катмыш авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Габделбәровка йөкләргә.

Катмыш авыл җирлеге
вазыйфаларын башкаручы  /Р.Р.Габделбәров/

1 нче кушымта

# Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | объектның исеме | Кадастр номеры | урнашу урыны адресы ( торак пункт/ур.) | Техник параметрлар (мәйдан/диаметр/биеклек/озынлыгы һ.б.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Суэтем башнясы | 16:26:060201:293 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Баскан авылы | Биеклеге 10,8 м | 1976 |
| 2 | Суэтем башнясы | 16:26:400301:74 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Еники Чишмә авылы | Куләме 60 м | 1976 |
| 3 | Суэтем башнясы | 16:26:400101:300 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Катмыш авылы | Биеклеге 15,0 м | 1976 |
| 4 | Су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4419 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Баскан авылы | озынлыгы 3495 м. | 1976 |
| 5 | Су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4420 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Катмыш авылы | Озынлыгы 4820 м. | 1976 |
| 6 | Су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4415 | Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Еники Чишмә авылы | Озынлыгы 3486 м. | 1976 |